**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 29 гыйнварындагы 249 номерлы карары**

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру турында**

Россия Федерациясе шәһәрләре арасында туризм өлкәсендә муниципальара хезмәттәшлекне үстерү, шулай ук туристлык индустриясе хезмәткәрләренең хезмәт дәрәҗәсен күтәрү һәм аларның үз эшчәнлекләрендә иң югары нәтиҗәләргә ирешүенә этәргеч бирү максатыннан **карар бирәм**:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV төбәкара һөнәри осталык фестивале турында нигезләмә (1 номерлы кушымта);

1.2. Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру буенча иҗтимагый советы составы (2 номерлы кушымта).

2. «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (А.А.Шавлиашвили) Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV төбәкара һөнәри осталык фестивален оештыруга һәм уздыруга вәкаләт бирергә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 декабрендәге 5035 номерлы «Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында “Кунакчыллык йолдызлары – 2024” III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 5467 номерлы, 2024 елның 28 декабрендәге 5483 номерлы, 2025 елның 10 гыйнварындагы 13 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р. Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы
249 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары — 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмә**

## I. Әлеге нигезләмәдә кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр

Нигезләмә шартларын бер мәгънәле аңлату максатыннан түбәндәге терминнар кулланыла:

- фестиваль – әлеге Нигезләмә нигезендә үткәрелә торган һәм сайлап алу этабын һәм төбәкара (финал) этабын үз эченә алган Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары –2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале;
- оештыручы – әлеге Нигезләмә нигезендә фестивальне оештыруны һәм уздыруны гамәлгә ашыручы «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе;
- жюри - экспертлардан һәм профессионаллардан торган, фестивальдә катнашучыларның нәтиҗәләрен бәяләргә вәкаләтле һәм иҗтимагый совет тарафыннан сайланган коллегиаль орган;
- жюри әгъзалары - билгеләнгән критерийлар нигезендә конкурс эшләрен бәяләүне гамәлгә ашыручы физик затлар;
- иҗтимагый совет - фестивальнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе вәкилләреннән төзелгән, фестиваль чараларын үткәрүдә һәм бәяләүдә катнашырга вәкаләтле, шулай ук жюри формалаштыруны һәм жюри әгъзаларын сайлауны гамәлгә ашыручы киңәшмә органы
- сайлап алу этабы - фестивальнең беренче этабы, анда катнашучыларның өй эшләре (видеоматериаллар) белән таныштыруы һәм жюриның аны бәяләве каралган;
- төбәкара (финал) этап - фестивальнең икенче этабы, аның барышында сайлап алу этабын уңышлы узган катнашучылар билгеләнгән тәртиптә үзләренә җиткерелгән бәяләү критерийлары нигезендә биремнәрне

үтиләр;

- бәяләү кәгазе - жюри әгъзалары тарафыннан башкарылган биремнәрне бәяләү критерийлары һәм процедурасы булган документ;
- катнашучы - билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм фестивальдә катнашу өчен гариза-анкета тапшырган физик зат.

## II. Гомуми нигезләмәләр

2.1. Әлеге нигезләмә Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары — 2025» IV төбәкара һөнәри осталык фестивален (алга таба – Фестиваль) уздыру тәртибен җайга сала, Фестивальнең максатларын һәм бурычларын, оештыру, үткәрү вакытын һәм анда катнашу шартларын, катнашу өчен гаризалар бирү тәртибен, бәйге нигезендә сайлап алу һәм Фестивальдә җиңүчеләрне бүләкләү тәртибен билгели.

2.2. Фестивальне оештыручы – Идел буе шәһәрләре ассоциациясе ярдәме белән «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Оештыручы).

2.3. Фестивальне оештыручы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- Фестивальдә катнашучыларның барысы өчен дә тигез шартлар;
- Фестивальне үткәрүдә ачыклык;
- Иҗтимагый совет оештыру һәм аның эшен оештыру, иҗтимагый совет тарафыннан жюриның фестиваль үткәрүне тәэмин итүче срокларда гадел сайлануы;
- Фестиваль нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны аларны рәсми рәвештә игълан итү көненнән иртәрәк хәбәр итүгә юл куймауны;
- Фестивальдә җиңү һәм приз яулаучылар дип танылган катнашучыларга бүләкләр тапшыру.

## III. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

3.1. Фестивальнең төп максатлары – Россия Федерациясенең Фестивальне уздыруда катнашу турында карар кабул иткән шәһәрләрендә туризмны үстерү өчен шартлар булдыру, туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү.

3.2. Фестивальнең бурычлары:

- Россия Федерациясе шәһәрләренең туристлык, ресторан һәм кунакханә ресурсларын популярлаштыру;
- - туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүгә һәм конкуренциягә сәләтен арттыруга ярдәм итү;
- - әлеге өлкә хезмәткәрләренең һөнәри белем, осталык һәм күнекмәләр дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук иҗади башлангычларын үстерү;
- - җәмәгатьчелектә туристлык һәм кунакчыллык индустриясе һөнәрләренә карата уңай фикер формалаштыру;
- - Россия шәһәрләренең туристларны җәлеп итүчәнлеген арттыру.

## IV. Фестиваль номинацияләре

Фестиваль унөч номинация буенча үткәрелә:

- «Иң яхшы портье»;
- «Иң яхшы җыештыручы»;
- «Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер»;
- «Ресторанның иң яхшы менеджеры»;
- «Иң яхшы официант»;
- «Иң яхшы бармен»;
- «Иң яхшы пешекче»;
- «Иң яхшы кондитер»;
- «Иң яхшы сити-блогер»;
- «Яшь йолдыз. Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер»;
- «Иң яхшы бариста»;
- «Иң яхшы маркетолог»;
- «Булачак кунакчыллык йолдызы. Иң яхшы официант».

## V. Фестивальдә катнашучылар

5.1. Фестивальдә номинацияләр буенча катнашу өчен Фестивальдә катнаша торган шәһәрләрнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләренең гариза-анкета тапшырган хезмәткәрләре чакырыла.

5.1.1. Фестивальдә номинацияләр буенча катнашучылар туризм һәм (яки) кунакчыллык өлкәсендә кимендә алты ай эш стажына ия булырга һәм хәзерге вакытта билгеләнгән номинациягә («Иң яхшы сити-блогер» номинациясеннән

тыш) туры килә торган белгечлек буенча эшләргә (шул исәптән берьюлы ике эштә һәм/яисә гражданлык-хокук килешүе буенча) тиеш.

5.1.2. Шәһәрләрнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре Фестивальдә номинацияләр буенча катнашу өчен һәр номинация буенча өчтән артык булмаган санда катнашучы тәкъдим итә ала.

5.2. «Яшь йолдыз. Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясендә катнашучылар – югары уку йортлары студентлары һәм урта һөнәри белем бирүче уку йортлары укучылары.

5.3. «Булачак кунакчыллык йолдызы. Иң яхшы официант» номинациясендә катнашучылар - урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы мәктәп укучылары.

5.4. Фестивальне оештыручылар, иҗтимагый совет һәм жюри әгъзалары Фестивальдә катнаша алмый.

5.5. Узган елгы Фестивальдә җиңгән физик затлар Фестивальнең элек җиңү яулаган номинациясендә катнаша алмый.

## VI. Иҗтимагый совет вәкаләтләре һәм эш тәртибе

6.1. Фестивальнең Иҗтимагый советы фестивальне оештыручылар, Идел буе шәһәрләре ассоциациясе һәм туристлык, ресторан һәм кунакханә бизнесы, иҗтимагый, уку һәм фәнни оешмалар вәкилләреннән (һәр оешмадан бердән артык вәкил түгел) төзелә һәм әлеге карар белән раслана.

6.2. Иҗтимагый совет 2026 елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча фестиваль жюрисын формалаштыру һәм раслау максатыннан утырыш үткәрә.

6.3. Жюри төзү һәм раслау иҗтимагый совет әгъзаларының тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6.4. Әгәр утырышта иҗтимагый совет әгъзаларының 50 проценттан артыгы катнашса, иҗтимагый совет утырышы тулы хокуклы була.

6.5. Иҗтимагый совет жюрины утырышта катнашучы иҗтимагый совет әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән кабул ителгән карарлар нигезендә ачык тавыш бирү юлы белән раслый.

6.6. Аерым номинацияләр буенча жюри әгъзалары саны – кимендә өч кеше.

6.7. Иҗтимагый советның жюри формалаштыру турындагы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа иҗтиматый совет рәисе 2026 елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча кул куя.

## VII. Фестиваль этаплары

7.1. Фестиваль ике этапта уздырыла: сайлап алу этабы һәм төбәкара (финал) этабы.

7.2. Сайлап алу этабын тәмамлау вакыты – 2026 елның 13 феврале (әзерлекне исәпкә алып). Сайлап алу этабы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- иҗтимагый совет тарафыннан фестивальне үткәрүне тәэмин итә торган срокларда (шул исәптән төбәкара этаптагы конкурс чараларын уздыру көненә кадәрге срокларда)жюри төзүне;
- 2026 елның 27 гыйнварыннан 2026 елның 30 гыйнварына кадәр фестивальдә катнашучылардан гариза-анкеталар кабул итү;
- бәяләү кәгазендәге билгеләнгән бәяләү критерийлары буенча жюриның өй эшен (видеоматериалларны) бәяләвен;
- сайлап алу этабы биремен бәяләү нәтиҗәләрен билгеләү һәм фестивальнең төбәкара этабына 2026 елның 13 февраленә кадәр узган катнашучыларны билгеләү.

7.3. Төбәкара (финал) этап 2026 елның 14 февраленнән 2026 елның 28 февраленә кадәр (әзерлекне исәпкә алып) уздырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- сайлап алу этабын уңышлы үткән катнашучылар исемлеген төзү;
- Казан шәһәрендә катнашучыларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелә торган бәяләү критерийлары нигезендә конкурс чаралары уздыру;
- фестивальнең нәтиҗәләрен билгеләү һәм җиңүчеләрне бүләкләү (2026 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча).

7.4. Гаризалар кабул итү барышында, шулай ук Фестивальнең сайлап алу этабын уздыру чорында иҗтимагый совет һәм жюри әгъзаларына Фестивальнең сайлап алу этабында катнашучы башка туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләрен эшкә яллау белән шөгыльләнү тыела.

7.5. Фестивальне оештыручы иҗтимагый совет составы һәм фестиваль жюрисы турында мәгълүматларны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында(www.kzn.ru) һәм Идел буе шәһәрләре ассоциациясе сайтында (www.agpsamara.ru) бастыра .

7.6. Фестивальне үткәргәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган жюри әгъзасының турыдан-туры яки читләтеп шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул анкета-гаризаларны карый башлаганчы бу хакта оештыручыга хәбәр итәргә тиеш.

## VIII. Фестивальнең сайлап алу этабын әзерләү һәм уздыру

8.1. Фестивальнең Иҗтимагый советы тарафыннан фестивальне оештыручы, Идел буе шәһәрләре ассоциациясе һәм туристлык, ресторан һәм кунакханә бизнесы, иҗтимагый, уку һәм фәнни оешмалар вәкилләреннән жюри төзелә.

8.2. Әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә күрсәтелгән номинацияләрдә фестивальдә катнашуга гариза-анкета әлеге нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасындагы форма буенча тутырыла һәм 8.2.1– 8.2.2 пунктларында күрсәтелгән документлар белән бергә түбәндәге интернет-сылтама буенча урнаштырылган гариза-анкетаның электрон формасын тутыру юлы белән электрон рәвештә җибәрелә: https://forms.yandex.ru/cloud/69201e1d49af4711331c94e8 .

Катнашучы гаризаны җибәреп, фестивальне үткәрү максатыннан, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон нигезендә, фестиваль оештыручысы тарафыннан бирелгән шәхси мәгълүматларны (Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә) эшкәртүгә, шул исәптән гариза-анкетаны эшкәртүгә, катнашучы белән аралашуга, нәтиҗәләрне бастырып чыгаруга һәм җиңүчеләрне бүләкләүгә ризалыгын раслый. Шәхси мәгълүматларны эшкәртү әлеге максатларга ирешү өчен кирәкле срок дәвамында башкарыла.

8.2.1. Фестивальдә әлеге нигезләмәнең IV бүлегендә күрсәтелгән номинацияләрдә катнашу өчен гариза-анкетага түбәндәге документлар (сканерланган jpeg форматындагы күчермәләр) теркәлә («Иң яхшы сити-блогер» номинациясеннән тыш):

- кунакчыллык өлкәсенә караган оешмалардагы эш урыныннан белешмә;
- белем алу турында диплом күчермәсе яки уку урыныннан белешмә;
- хезмәт кенәгәсенең оешма мөһере белән расланган күчермәсе;
- һөнәри керемгә салым түләүче физик зат (үзмәшгуль) сыйфатында номинациягә туры килә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырган очракта – физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую турында белешмә (КНД 1122035 формасы буенча).

8.2.2. Катнашучы теләге буенча гариза-анкетага грамоталар, дипломнар, рәхмәт хатлары, бүләкләр турындагы таныклыклар, бәяләмәләр (булган очракта) күчермәләре, шул исәптән һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашу турында документ күчермәләре теркәлергә мөмкин.

8.3. Фестивальнең барлык номинацияләре буенча гариза-анкеталар оештыручы тарафыннан 2026 елның 30 гыйнварына кадәр (кертеп) кабул ителә.

8.4. Әгәр гариза 8.3 пунктында күрсәтелгән вакыттан соң бирелгән булса, әлеге гариза каралмый.

8.5. Фестивальне оештыручы гариза-анкетада күрсәтелә торган электрон почта адресына хат белән гаризалары 8.3 пунктында күрсәтелгән сроктан соң кергән катнашучыларга гариза алынганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча Фестивальнең сайлап алу этабына кертелмәү турында хәбәр итә.

8.6. 22026 елның 6 февраленә кадәр фестивальне оештыручы фестивальдә катнашучыларга «өй эше» сайлап алу этабы биремен һәм электрон почта аша аны бәяләү критерийларын җибәрә.

8.7. Сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары Фестивальнең һәр номинациясе өчен билгеләнә һәм әлеге Нигезләмәгә 3-16 номерлы кушымталарда китерелә.

8.8. Фестиваль катнашучысы 2026 елның 12 февраленә кадәр «Яндекс.Диск» файллар хостингында (disk.yandex.ru) «Өй эше» сайлап алу этабы биремнәрен үтәү буенча материаллар урнаштырырга тиеш. Фестивальдә катнашучылар «Өй эше» сайлап алу этабы биремнәрен үтәү буенча урнаштырылган материалларына сылтамаларны исем-фамилиясен, атасының исемен, тәкъдим иткән шәһәрнең исемен, номинацияне күрсәтеп, zv.g@tatar.ru электрон почта адресына җибәрәләр..

8.9. Фестивальне оештыручы 2026 елның 12 февраленә кадәр Фестивальдә катнашучылардан алар тарафыннан «Өй эше» сайлап алу этабы биремнәренең үтәлеше турында мәгълүмат җыя һәм аны жюри әгъзаларына тапшыра.

8.10. Жюри әгъзалары 2026 елның 12 февраленнән 13 февраленә кадәр:

- сайлап алу этабындагы биремнең Фестивальдә катнашучылар тарафыннан үтәлешен һәм аларның һөнәри осталыгын бәяли;
- Фестивальнең төбәкара этабына узган катнашучыларын билгели.

8.11. Жюри әгъзалары утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы булып санала.

8.12. Жюри карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Сайлап алу этабында үз номинациясендә «Өй эшен» үтәгән барлык катнашучылар әлеге Нигезләмәгә 3 – 16 номерлы кушымталарда күрсәтелгән критерийлар нигезендә гариза-анкетада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча фестивальнең финал ярышларында катнашырга чакырыла.

8.13. Жюри карары беркетмә белән 2026 елның 14 февраленнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

8.14. Жюри фестивальнең сайлап алу этабы тәмамланганнан соң өч көн эчендә фестивальне оештыручыга барлык номинацияләр буенча төбәкара этапка кертелгән катнашучылар турында мәгълүмат җибәрә.

8.15. Фестивальне оештыручы жюри әгъзалары карар кабул иткәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алу этабын узмаган катнашучыларга гариза-анкетада күрсәтелгән электрон почта адресына хат белән фестивальнең финал этабына кертелмәү турында хәбәр итә.

8.16. Биремне бәяләү нәтиҗәләре, жюриның җиңүчене билгеләү турындагы карары белән килешмәгән очракта, катнашучы иҗтимагый советка апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, сайлап алу этабы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, өч календарь көн эчендә бирелә. Апелляцияне Оештыручы апелляция теркәлгәннән соң биш тәүлек эчендә карап тикшерә.

## IX. Фестивальнең төбәкара (финал) этабын әзерләү һәм уздыру

9.1. Фестивальнең төбәкара этабын уздырганда Оештыручының төп функцияләре:

- Фестивальнең төбәкара этабында катнашучылар исемлеген төзү (Фестиваль финалына үткәннәр);
- Фестивальнең аерым номинацияләре буенча конкурс чараларын уздыру графигын һәм урынын раслау;
- конкурс чараларын әзерләү һәм үткәрү.

9.2. 2026 елның 19 февраленә кадәр Фестивальне оештыручы, Фестивальнең сайлап алу этабында катнашып, төбәкара этапка узучыларга Фестивальнең төбәкара этабын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат җиткерә. Фестивальнең төбәкара этабын уздыру өчен башка дата билгеләнгән очракта, Фестивальне оештыручы тарафыннан Фестивальдә катнашучыларга Фестивальнең төбәкара этабын уздыру датасы һәм урыны

турында, төбәкара этапны уздыру көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча, электрон почта аша хәбәр ителә.

9.3. Фестивальнең финал этабында катнашучылар төбәкара этап уздырыла торган шәһәргә кадәр бару, анда яшәү һәм кайту белән бәйле чыгымнарны үзләре каплый.

9.4. Фестивальне оештыручы фестивальнең аерым номинацияләре өчен төбәкара этапны гала-кичке аш формасында уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

## X. Фестивальнең төбәкара этабын үткәрү һәм фестиваль җиңүчеләрен билгеләү тәртибе

10.1. Катнашучыларның һөнәри осталык дәрәҗәсен бәяләү Фестивальне оештыручы тарафыннан билгеләнә торган импровизацияләнгән эш урыннарында үткәрелә.

10.2. Фестивальнең төбәкара этабында катнашучылар жюри әгъзалары тарафыннан һәр номинация өчен эшләнгән бәяләү критерийлары буенча бәяләнә. Бәяләү критерийлары фестиваль жюрисы тарафыннан раслана һәм фестивальнең практик өлеше башланырга җиде көн кала Фестиваль сайтында: звездыгостеприимства.рф урнаштыру юлы белән катнашучыларга җиткерелә. Катнашучының рейтингы жюри әгъзалары биргән баллар суммасына тигез.

Жюри әгъзалары биргән баллар суммасына катнашучының төбәк/шәһәр территориясендә һөнәри осталык конкурсында җиңүче яки призер дипломы булганда 1 балл өстәлә.

10.3. Жюри утырышын уздыру өчен кворум жюри әгъзалары санының яртысыннан да ким булмаска тиеш.

10.4. Конкурста катнашучыларның баллары тигез булса, карар жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

10.5. Төбәкара этап гала-кичке аш рәвешендә үткәрелсә, Фестивальдә катнашучыларның һөнәри осталык дәрәҗәсен бәяләү гала-кичке ашта катнашучылар арасында һәр номинациягә карата аерым аноним тавыш бирү нәтиҗәләре буенча башкарыла. Гала-кичке ашка килүчеләр арасында аноним тавыш бирү нәтиҗәләре буенча иң күп тавыш җыйган Фестивальдә катнашучылар җиңүче дип таныла.

10.6. Жюри утырышы көнендә жюри әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасы буенча катнашучыларның рейтингын формалаштырыла.

10.7. Утырыш көнендә жюри әгъзалары иң күп балл җыйган фестиваль җиңүчеләрен һәм призерларын билгели.

10.8. Фестиваль нәтиҗәләре буенча һәр номинация буенча җыелма ведомость рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан конкрет номинациянең жюри әгъзалары тарафыннан имзалана.

10.9. Фестивальне оештыручы 2026 елның 28 февраленә кадәр фестивальнең барлык номинацияләрдәге нәтиҗәләрен Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) бастыра.

## XI. Фестивальгә нәтиҗәләр ясау һәм аның җиңүчеләрен бүләкләү

11.1. Фестивальнең төбәкара этабы йомгаклары буенча катнашучыларга һәр номинациядә I, II, III урыннар бирелә.

11.2. Фестивальнең төбәкара этабында номинация буенча I урын яулаган җиңүчегә «Кунакчыллык йолдызы – 2025» дипломы, акчалата бүләк, кубок һәм башка истәлекле бүләкләр тапшырыла.

11.3. Фестивальнең һәр номинациясендә җиңүчеләргә 50 000 (илле мең) сум күләмендә акчалата бүләк бирелә.

11.3.1. Җиңүче– физик затлар өчен бүләк суммасы физик затлар керемenә салымны тотып калып исәпләнгән һәм җиңүчеләргә түләү өчен ахыргы сумма булып тора.

11.3.2. Фестивальдә җиңүчеләргә бүләкләүне түләүче оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 24 статьясы нигезендә салым агенты булып тора, физик затлар керемenә салына торган салымны тотып кала һәм бюджетка 13 процент күләмендә күчерә, җиңүчегә бүләкнең тулы суммасын өстәмә салым йөкләмәләреннән башка түләүне тәэмин итә.

11.4. Фестивальнең төбәкара этабында II һәм III урыннар яулаган катнашучыларга дипломнар һәм башка истәлекле бүләкләр тапшырыла.

11.5. Җиңүчеләргә акчалата бүләк банк реквизитлары буенча 2026 елның 4 апреленнән дә соңга калмыйча түләнә. Шул ук вакытта банк реквизитлары оештыручы тарафыннан 2026 елның 31 мартыннан да соңга калмыйча җиңүчеләрдән өстәмә рәвештә сорала.

11.6. Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы 2026 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча булырга тиеш.

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары-2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале катнашу өчен гариза-анкета**

| | |
|---|---|
| | Фотосурәт 3х4 см* |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Туу датасы | |
| Җенесе | |
| Туу урыны | |
| Тәкъдим ителә торган шәһәр | |
| Элемтә өчен телефон номеры | |
| E-mail | |
| Катнашу өчен номинация | |
| Тәкъдим ителә торган оешма | |
| Биләгән вазыйфасы | |
| Белеме (уку йортының тулы атамасы, тәмамлау елы, белгечлек) | |
| Эш стажы (гомуми һәм тармактагы эш стажын | |

| | |
|---|---|
| күрсәтергә) | |
| Чит телләрне белү турында мәгълүмат (күрсәтергә) | |
| Һөнәри конкурсларда катнашу турында мәгълүмат | |
| Һөнәри бүләкләр, бүләкләнү датасы | |
| Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | |
| Өстәмә мәгълүмат (квалификация күтәрү, бүләкләр, рәхмәт хатлары, клиентларның һәм партнерларның бәяләмәләре (шул исәптән социаль челтәрләрдәге), проектларда катнашу, видеопрезентация һ.б.) | |

Әлеге гаризага түбәндәге документлар (яки аларның сканерланган jpeg, pdf, doc форматларындагы күчермәләре) теркәлә:

- 3x4 см үлчәмдәге фотосурәт;
- кунакчыллык һәм туризм өлкәсенә караган оешмалардагы эш урыныннан белешмә;
- белем алу турында диплом күчермәсе/уку урыныннан белешмә;
- өстәмә белем алу, квалификация күтәрү, курслар, стажировкалар узу турында һәм башка документларның күчермәләре (булган очракта);
- хезмәт кенәгәсенең оешма мөһере белән расланган күчермәсе;
- башка материаллар (гариза бирүче теләге буенча).

_______________________________ _______________________________

катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме — катнашучының имзасы

2026 елның «______» ______________ Эш бирүче М.У.

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 2 номерлы кушымта

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,

________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

шәхесне раслаучы документ:_______________________________________________
(документ төре)

кем тарафыннан бирелгән:_________________________________________________
(кем тарафыннан һәм кайчан)

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ________________________________________,

минем шәхси мәгълүматларымны (фамилиям, исемем, атамның исеме; туу датасы; элемтә телефоны (өй/мобиль/эш); фотография куллану; белем турындагы документлар; хезмәт кенәгәсе; квалификация күтәрүне раслаучы документлар; социаль челтәрләргә сылтамалар; яшәү адресы; эшләү урыны (уку), вазыйфам, банк счетлары турындагы мәгълүмат) Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале оештыручысы («Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе, 420111, Казан шәһәре, Кремль урамы, 11), шул исәптән жюри һәм экспертлар тарафыннан эшкәртүгә ризамын.

Оештыручыга үземнең шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, шул исәптән түбәндәге гамәлләрне башкаруга: шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, шәхси мәгълүматларны юк итү) (югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны эшкәртү ысуллары тасвирламасы 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законда китерелгән), шулай ук югарыдагы органнарның норматив документларында һәм законнарда билгеләнгән очракларда өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.

Әлеге ризалык вакыты чикләнми.

Әлеге ризалык якларның килешүе буенча теләсә кайсы вакытта минем тарафыннан кире кайтарып алынырга мөмкин. Бирелгән мәгълүматлардан хокуксыз файдаланган очракта ризалык язма гариза белән кире алына.

«____»______________ 20    ел.

___________________          _______________________
(имза)          (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон нигезләмәләре белән таныштым, шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылды.

«____»______________ 20    ел.          ___________________
_______________________

(имза)          (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы
249 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивален уздыру буенча иҗтимагый совет составы**

| | |
|---|---|
| Лодвигова Евгения Анатольевна | иҗтимагый совет җитәкчесе, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Шавлиашвили Александр Акакиевич | иҗтимагый совет җитәкчесе урынбасары, «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе директоры |

Иҗтимагый совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Сәлмәнова Гүзәл Әсгать кызы | «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенең туристлык индустриясен үстерү бүлегенең баш эксперты |
| Устюжанин Андрей Владимирович | «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенең грантлы һәм конкурслы программаларны гамәлгә ашыру һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге башлыгы |
| Әхмәтшина Алсу Ринат кызы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Идарә, икътисад һәм финанслар институты директоры (килешү буенча) |
| Гаязов Зөфәр Фәдип улы | Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты (килешү буенча) |
| Ковалева Фәридә Рәхиб кызы | «Халыкара сервис көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Прусс<br>Нэлла Матвеевна | «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Тимирясова<br>Асия Витальевна | «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (ИЭУП)» югары белем бирүче хосусый мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Репринцев Владимир<br>Григорьевич | Идел буе шәһәрләре ассоциациясенең башкарма директоры (килешү буенча) |
| Борһанов<br>Рәфис Тимерхан улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |

_______________

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык
йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык
төбәкара фестивале турында
нигезләмәгә 3 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы портье» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| **№ т/б** | **Бәяләү критерие** | **Балларның максималь саны** |
|---|---|---|
| 1 | Бизәлеше, матурлыгы, дизайны | 1 |
| 2 | Тәкъдим ителгән материалны бирү эзлеклелеге | 2 |
| 3 | Темага туры килүе | 3 |
| 4 | Креативлык, иҗади якын килү | 1 |
| 5 | Вакыт регламентын үтәү | 3 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **10** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык
йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык
төбәкара фестивале турында
нигезләмәгә 4 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы җыештыручы» номинациясе буенча биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Үзенчәлекле булу | 3 |
| 2 | Урын-җирне җыештыру | 3 |
| 3 | Концепциягә туры килү | 1 |
| 4 | Видеоматериалның сыйфаты | 2 |
| 5 | Катнашучының тышкы кыяфәте | 1 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **10** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 5 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Эчке һәм керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясе буенча беремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Балларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Видеороликта күрсәтелгән объектларның төбәкнең социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни үзенчәлекләренә туры килүе | 1 – төбәкнең географик урынын билгеләү;<br>1 - төбәк тарихы белән таныштыру;<br>1 – төбәкнең төп истәлекле урыннары турында мәгълүмат бирү;<br>1 – төбәкнең социаль-икътисади яктан төзелешен билгеләү;<br>1 – төбәкнең мәдәни-тарихи үзенчәлекләрен күрсәтү;<br>1 – климат үзенчәлекләрен һәм сезонлылыкны билгеләү;<br>1 – төбәк объектларының социаль-икътисади үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге; 1 – төбәк объектларының тарихи-мәдәни үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге | 8 |
| 2 | Видеороликта тәкъдим ителгән объектларның төрлелеге | 1 – төбәктәге туризм төрләрен санап чугу;<br>1 – объектларның төбәктәге туризм төрләренә туры килүе;<br>1 – социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни объектларга | 4 |

| №<br>т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Балларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| | | баруның сезонга бәйле булуы;<br>1 – төбәкнең туристлык мөмкинлекләре нигезендә андагы истәлекле урыннарның үзенчәлекләрен аерып күрсәтү | |
| 3 | Видеороликта туристлык юнәлешен тәкъдим итүнең нәтиҗәлелеге | 0 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынмаган. Видеоролик нәтиҗәле түгел, сату өчен этәргеч булып тормый, кызыксыну уятмый;<br>1 – төбәкнең төп үзенчәлекләре өлешчә исәпкә алынган. Видеоролик өлешчә нәтиҗәле, сату өчен өлешчә этәргеч булып тора, бераз кызыксыну уята;<br>2 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынган. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, кызыксыну уята;<br>3 – төбәкнең төп үзенчәлекләре генә түгел, артык билгеле булмаган, әмма җәлеп итә алырлык мөмкинлеккә ия яклары да күрсәтелгән. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, зур кызыксыну уята | 6 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **18** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 6 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Ресторанның иң яхшы менеджеры» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Мәсьәләләрнең асылын тулысынча белү | 3 |
| 2 | Ачыклаучы сорауларга җаваплар | 2 |
| 3 | Җавапларны мисаллар белән тулыландыру | 2 |
| 4 | Килеп туган хәлдән үзенчәлекле чыгу | 2 |
| 5 | Сөйләмнең грамоталы булуы | 1 |
| 6 | Гамәли бирем | 10 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **20** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 7 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы официант» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| **Кызыл шәрабны декантацияләү** | | 15 |
| 1 | Санитария нормаларын үтәү | 3 |
| 2 | Декантация өчен эш өстәлен һәм инвентарьны әзерләү | 3 |
| 3 | Шәрабны тәкъдим итү | 3 |
| 4 | Декантацияләү техникасы | 3 |
| 5 | Шәрабны салу | 3 |
| **Тастымалларны төрү** | | 15 |
| 1 | Төрелгән тастымаллар саны | 3 |
| 2 | Тастымалларны пөхтә һәм катлаулы итеп төрү | 5 |
| 3 | Креативлык | 4 |
| 4 | Өстәмә аксессуарлар куллану | 2 |
| 5 | Санитария нормаларын үтәү | 1 |
| **Өстәлне сервировкалау** | | 25 |
| 1 | Официантның тышкы кыяфәте | 3 |
| 2 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| 3 | Өстәл сервировкалаганда эзлеклелекне саклау | 4 |
| 4 | Өстәлне әзерләү һәм ашъяулык җәю | 4 |
| 5 | Өстәл сервировкасының тәкъдим ителгән менюга туры килүе | 4 |
| 6 | Сервировкалау геометриясе | 4 |
| 7 | Өстәмә аксессуарлардан файдалануның максатка ярашлы булуы | 2 |
| 8 | Өстәлне бизәү предметларын дөрес файдалану | 2 |

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| **Кунакларга хезмәт күрсәтү** | | 30 |
| 1 | Кунакларны чакыру. Аларны өстәл янына утырту | 3 |
| 2 | Официантның кунаклар белән аралашуы, менюны тәкъдим итү | 4 |
| 3 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү эзлеклелеген саклау | 5 |
| 4 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү техникасы | 5 |
| 5 | Кулланылган савыт-сабаны җыештыру техникасы | 5 |
| 6 | Өстәлне десерт китерүгә әзерләү һәм аны табынга бирү | 2 |
| 7 | Менюда каралган алкогольсез коктейль һәм бармен тарафыннан әзерләнгән эчемлекләрне тәкъдим итү һәм табынга бирү техникасы | 4 |
| 8 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **Өстәл җыештыру** | | 15 |
| 1 | Кунакларны озату | 2 |
| 2 | Өстәлдә калган предметлар һәм ризык | 2 |
| 3 | Калган савыт-сабаны җыю техникасы | 4 |
| 4 | Өстәлне җыештыру өчен махсус җайланмалардан һәм предметлардан файдалану | 2 |
| 5 | Ашъяулыкны җыю техникасы | 3 |
| 6 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **100** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 8 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы бармен» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Тышкы кыяфәт | 0-5 |
| 2 | Чыгыш ясау өчен эш урынының әзерлеге | 0-5 |
| 3 | Коктейль әзерләү технологиясен үтәү | 0-10 |
| 4 | Катнашучының үз-үзен ышанычлы тотуы | 0-10 |
| 5 | Коктейльне табынга үзенчәлекле бирү | 0-10 |
| 6 | Коктейльне билгеләнгән вакыт эчендә әзерләү һәм тәкъдим итү | 0-5 |
| 7 | Коктейль әзерләгән вакытта эш урынының чисталыгы | 0-10 |
| 8 | Коктейльне бокалларга тигез салмау, шейкерда калган өлеше | 0-5 |
| 9 | Коктейль әзерләү һәм аны бирү барышында гигиена нормаларын үтәү | 0-5 |
| 10 | Коктейльне презентацияләү | 0-10 |
| 11 | Коктейльне бәяләү | 0-10 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **85** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 9 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы пешекче» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Әзерләнгән ризыкның тышкы күренеше | 5 |
| 2 | Төсе | 5 |
| 3 | Тенденцияләрне үтәү | 5 |
| 4 | Текстурасы (консистенциясе) | 5 |
| 5 | Исе | 5 |
| 6 | Тәме | 20 |
| 7 | Ризыкны әзерләү идеясе һәм аны тәкъдим итү | 5 |
| 8 | Эш урынын оештыру | 5 |
| 9 | Санитария-гигиена кагыйдәләрен үтәү | 5 |
| 10 | Һөнәри алымнарга ия булу | 5 |
| 11 | Продуктларны рациональ куллану | 5 |
| 12 | Җиһазларны дөрес куллану, хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү | 5 |
| 13 | Катнашучының тышкы кыяфәте | 5 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **80** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 10 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы кондитер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Гигиена, эш урынын оештыру (mise en place), продуктны рациональ куллану | 0-10 |
| 2 | Һөнәри яктан дөрес әзерләү, һөнәри осталык, ризыкны әзерләүнең катлаулы булуы | 0-25 |
| 3 | Презентация һәм композиция (презентация өстәле) | 0-15 |
| 4 | Әзерләнгән ризыкның тәме | 0-50 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **100** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 11 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2023» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы сити-блогер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Контент (темага туры килү, уникальлек, урынның/маршрутның сирәк очравы) | 50 |
| 2 | Башкару сыйфаты | 50 |
| 3 | Чит ил тамашачысына чыгу (*) | 10* |
| **БАРЛЫГЫ** | | **100 (110)** |

*мәҗбүри булмаган критерий

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 12 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Яңа йолдыз. Эчке һәм керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Балларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Видеороликта күрсәтелгән объектларның төбәкнең социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни үзенчәлекләренә туры килүе | 1 – төбәкнең географик урынын билгеләү;<br>1 - төбәк тарихы белән таныштыру;<br>1 – төбәкнең төп истәлекле урыннары турында мәгълүмат бирү;<br>1 – төбәкнең социаль-икътисади яктан төзелешен билгеләү;<br>1 – төбәкнең мәдәни-тарихи үзенчәлекләрен күрсәтү;<br>1 – климат үзенчәлекләрен һәм сезонлылыкны билгеләү;<br>1 – төбәк объектларының социаль-икътисади үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге; 1 – төбәк объектларының тарихи-мәдәни үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге | 8 |
| 2 | Видеороликта тәкъдим ителгән объектларның төрлелеге | 1 – төбәктәге туризм төрләрен санап чугу;<br>1 – объектларның төбәктәге туризм төрләренә туры килүе;<br>1 – социаль-икътисади һәм | 4 |

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Балларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| | | тарихи-мәдәни объектларга баруның сезонга бәйле булуы; 1 – төбәкнең туристлык мөмкинлекләре нигезендә андагы истәлекле урыннарның үзенчәлекләрен аерып күрсәтү | |
| 3 | Видеороликта туристлык юнәлешен тәкъдим итүнең нәтиҗәлелеге | 0 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынмаган. Видеоролик нәтиҗәле түгел, сату өчен этәргеч булып тормый, кызыксыну уятмый;<br>1 – төбәкнең төп үзенчәлекләре өлешчә исәпкә алынган. Видеоролик өлешчә нәтиҗәле, сату өчен өлешчә этәргеч булып тора, бераз кызыксыну уята;<br>2 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынган. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, кызыксыну уята;<br>3 – төбәкнең төп үзенчәлекләре генә түгел, артык билгеле булмаган, әмма җәлеп итә алырлык мөмкинлеккә ия яклары да күрсәтелгән. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, зур кызыксыну уята | 6 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **18** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 13 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы бариста» (техниканы бәяләү) номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| **Шәһәр** | **катнашучы фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Судьяның исеме, фамилиясе, атасының исеме** |
|---|---|---|
| | | |
| **1 нче өлеш. Чыгыш башына станцияне бәяләү** | | |
| **Бәяләү критерие** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Чыгыш башына станция чисталыгы / чиста чүпрәкләр | 10 | |
| **2 нче өлеш. Эспрессо бәяләү** | | |
| **Бәяләү критерие (техник күнекмәләр)** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Группаны юу | 1 | |
| Дозалауга кадәр коры/чиста фильтр кәрзине | 1 | |
| Дозалаудан/тарттырылганнан соң яраклы кофе калдыклары | 10 | |
| Тотрыклы дозалау һәм төйгечләп тыгызлау | 10 | |
| Портафильтрны чистарту (куйганчы) | 1 | |
| Кую һәм тоткарсыз агызу | 1 | |
| Экстракция вакыты (аерма өч секундтан артмый) | 1 | |
| **3 нче өлеш. Сөт эчемлеген бәяләү** | | |
| **Бәяләү критерие (техник күнекмәләр)** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Группаны юу | 1 | |
| Дозалауга кадәр коры/чиста | 1 | |

| | | |
|---|---|---|
| фильтр кәрзине | | |
| Дозалаудан/тарттырылганнан соң яраклы кофе калдыклары | 10 | |
| Тотрыклы дозалау һәм төйгечләп тыгызлау | 10 | |
| Портафильтрны чистарту (куйганчы) | 1 | |
| Кую һәм тоткарсыз агызу | 1 | |
| Экстракция вакыты (аерма өч секундтан артмый) | 1 | |
| **Бәяләү критерие (сөт)** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Чыгыш башында буш/чиста питчер | 1 | |
| Сөтне күбекләндергәнче пар үткәрү | 1 | |
| Күбекләндергәч пар җибәрү җайланмасын чистарту | 1 | |
| Сөтне күбекләндергәч пар үткәрү | 1 | |
| Яраклы сөт калдыклары | 1 | |
| **4 нче өлеш. Авторлык эчемлеген бәяләү** | | |
| **Бәяләү критерие (техник күнекмәләр)** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Группаны юу | 1 | |
| Дозалауга кадәр коры/чиста фильтр кәрзине | 1 | |
| Дозалаудан/тарттырылганнан соң яраклы кофе калдыклары | 10 | |
| Тотрыклы дозалау һәм төйгечләп тыгызлау | 10 | |
| Портафильтрны чистарту (куйганчы) | 1 | |
| Кую һәм тоткарсыз агызу | 1 | |
| Экстракция вакыты (аерма өч секундтан артмый) | 1 | |
| **5 нче өлеш. Техниканы бәяләү** | | |
| **Бәяләү критерие (техник күнекмәләр)** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Станциядә эшне оештыру/ чыгыштан соң станциянең чисталыгы | 10 | |
| Портафильтрның чиста борыннары/ | 1 | |

| | | |
|---|---|---|
| портафильтр борыннары кофе тарттыру дозаторына эләкмәгән | | |
| Чыгыш вакытында гигиена | 1 | |
| Сөлгеләрне дөрес куллану | 1 | |
| **Балларның максималь саны** | **113** | **БАРЛЫГЫ** |
| | | |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 14 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы бариста» (тәмне бәяләү) номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| **Эспрессо. 1 нче өлеш – презентация** | | |
|---|---|---|
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Сайланган рецептураны тәкъдим итү (рецепт / су / температура) | 5 | |
| Букетны тасвирлау төгәллеге (әчелеге / татлылык / ачы тәме) (характер / декрипт) | 10 | |
| **Эспрессо. 2 нче өлеш – эчемлек** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Кремы | 5 | |
| Тәмнең тасвирлауга туры килүе | 5 | |
| Тәмнәрнең балансы һәм комбинациясе (әчелеге / татлылык / ачы тәме) | 5 | |
| Тәмне кабул итү (характер) | 5 | |
| Калган тәм | 5 | |
| Эчемлек җисеменең рәхәтлеге / тактильлеге (авырлыгы + текстурасы + финиш) | 10 | |
| **Сөтле эчемлек. 1 нче өлеш – презентация** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Сайланган рецептураны тәкъдим итү (рецепт / сөт / температура) | 5 | |
| Дескрипторларны тасвирлау төгәллеге | 10 | |
| **Сөтле эчемлек. 2 нче өлеш – эчемлек** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның** | **БАРЛЫГЫ** |

| | максималь саны | |
|---|---|---|
| Визуаль бәяләү: бирелгән рәсемгә туры килү | 5 | |
| Рәсемнең төгәллеге / контрастлыгы / симметриясе | 10 | |
| Тәмнең тасвирлауга туры килүе | 10 | |
| Тәмне тоемлау (текстура / температура / баланс) | 10 | |
| **Авторлык эчемлеге. 1-нче өлеш – презентация** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Сайланган рецептураны тәкъдим итү (рецепт / су / температура) | 5 | |
| Букетны тасвирлау төгәллеге | 10 | |
| **Авторлык эчемлеге. 2 нче өлеш – эчемлек** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Хуш ис | 5 | |
| Тәмнәрнең балансы һәм комбинациясе | 5 | |
| Тәмне тоемлау | 5 | |
| Калган тәм | 5 | |
| Әчелеге | 5 | |
| Җисеме | 5 | |
| Тәмнең тасвирлауга туры килүе | 10 | |
| **Барлык эчемлекләр өчен** | | |
| **Бәяләү критерийлары** | **Балларның максималь саны** | **БАРЛЫГЫ** |
| Өч эчемлек буенча гомуми тәэсир: хезмәт күрсәтү, бирү, профессиональлек | 30 | |
| **Балларның максималь саны** | **185** | **БАРЛЫГЫ** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык
йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык
төбәкара фестивале турында
нигезләмәгә 15 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Иң яхшы маркетолог» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| **№ т/б** | **Бәяләү критерие** | **Балларның максималь саны** |
|---|---|---|
| 1 | Продуктны һәм аудиторияне аңлау | 15 |
| 2 | Биремне дөрес кую | 10 |
| 3 | Стратегия һәм креативлык | 25 |
| 4 | Инструментлар һәм бүрәнкә | 20 |
| 5 | Нәтиҗәләр һәм үлчәнеш | 25 |
| 6 | Презентациянең сыйфаты | 5 |
| 7 | Стратегик эффект һәм брендка йогынтысы | 10 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **110** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестивале турында нигезләмәгә 16 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2025» IV һөнәри осталык төбәкара фестиваленең «Булачак кунакчыллык йолдызы. Иң яхшы официант» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| **Тастымалларны төрү** | | 15 |
| 1 | Төрелгән тастымаллар саны | 3 |
| 2 | Тастымалларны пөхтә һәм катлаулы итеп төрү | 5 |
| 3 | Креативлык | 4 |
| 4 | Өстәмә аксессуарлар куллану | 2 |
| 5 | Санитария нормаларын үтәү | 1 |
| **Өстәлне сервировкалау** | | 25 |
| 1 | Официантның тышкы кыяфәте | 3 |
| 2 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| 3 | Өстәл сервировкалаганда эзлеклелекне саклау | 4 |
| 4 | Өстәлне әзерләү һәм ашъяулык җәю | 4 |
| 5 | Өстәл сервировкасының тәкъдим ителгән менюга туры килүе | 4 |
| 6 | Сервировкалау геометриясе | 4 |
| 7 | Өстәмә аксессуарлардан файдалануның максатка ярашлы булуы | 2 |
| 8 | Өстәлне бизәү предметларын дөрес файдалану | 2 |
| **Кунакларга хезмәт күрсәтү** | | 30 |
| 1 | Кунакларны чакыру. Аларны өстәл янына утырту | 3 |
| 2 | Официантның кунаклар белән аралашуы, менюны тәкъдим итү | 4 |
| 3 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү эзлеклелеген | 5 |

| №<br>т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| | саклау | |
| 4 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү техникасы | 5 |
| 5 | Кулланылган савыт-сабаны җыештыру техникасы | 5 |
| 6 | Өстәлне десерт китерүгә әзерләү һәм аны табынга бирү | 2 |
| 7 | Менюда каралган алкогольсез эчемлекләрне тәкъдим итү һәм бирү техникасы | 4 |
| 8 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **Өстәл җыештыру** | | 12 |
| 1 | Кунакларны озату | 2 |
| 2 | Өстәлдә калган предметлар һәм ризык | 2 |
| 3 | Калган савыт-сабаны җыю техникасы | 4 |
| 4 | Өстәлне җыештыру өчен махсус җайланмалардан һәм предметлардан файдалану | 2 |
| 5 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **83** |